ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2020 елда Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Урмандәй авыл җирлегенең
Сосновка һәм Сидулово - Ерыклы
торак пунктларда авылында
гражданнарның үзара салымын
кертү турында

2019 елның 26 ноябре № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлегенең Савгач авылында гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлеге Сосновка һәм Сидулово - Ерыклы торак пунктлары территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада укучы студентлардан тыш, 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- торак пункт чикләрендә юл полотносы урнаштыру;

2) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, су бүлү, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

- Сидул-Ерыклы поселогындагы су башнясына торба салу.

3. Әлеге карарны Урмандәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының интернет челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru .

Урмандәй авыл җирлеге башлыгы: В. З. Николаев